# Дидактик уеннар:
# “Күчмә һәм кышлаучы кошлар”





**Уенны төзүче:Гатина Г.М.**

**2016 ел**

**Максат:** балаларның кышлаучы һәм күчмә кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү.

**Бурычлар:**

1. Кош исемнәрен дөрес әйтү һәм сөйләмдә дөрес куллануга ирешү;тышкы билгеләренә (төсе, зурлыгына) карап кышлаучы,күчмә кошларны аерып күрсәтә белү күнекмәләрен ныгыту;
2. Балаларның фикерләү сәләтен үстерү; җөмләләр төзү, ишетеп аңлау, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү;
3. Кошларга карата кайгыртучанлык, сак мөнәсәбәт хисләре тәрбияләү.

# Дидактик уен «Җимлектә кошлар».

**Җиһаз:** җимлек,кышлаучы кош рәсемнәре.

**Уен барышы:** тәрбияче балаларга кошлар турында табышмак укый,балалар  җимлектән шул кошны табып алалар һәм шул кош турында сөйлиләр.





# Сүзле уен: “Килегез,кил,кошкайлар” шигыре буенча.

**Уен барышы: балалар сүзле уен барышында кошларны танып белергә  һәм җимлеккә киттереп куярга тиеш.**

**Кыш җиттеме – кошлар өчен**
**Без ашханә ачабыз:**
**Җимлекләр ясап әләбез,**
**Кошларны ашатабыз.**
**Килегез, кил кошкайлар,**
**Сез бит безнең дускайлар.**
**Бакчабызга кунызыгыз,**
**Көн дә кунак булыгыз.**

**Песнәк, песнәк, кил тизрәк,җим сибәм сиңа әзрәк.**
**Чыпчык, чыпчык-чык-чырык,җим сиптем, кил тиз очып!**
**Гөлдер,гөлдер күгәрчен сибәмен кабак төшен.**
**Тукран,тукран,син кара,кабып кал азык барда.**
**Кызылтүшем оялма,җим сибәмен бер оя.**

# Дидактик уен: «Кошлар ояда»

**Җиһаз:** агач макеты,кышлаучы һәм күчмә кош рәсемнәре.

**1 вариант. “Кайсы кош  очып китте?”**

Уен барышы: Күзләрне йомабыз, көчле җил чыкты һәм бер кош очып китте.

**2 вариант. “Кошларны аер”**

Уен барышы:бала агачка кышлаучы (яки күчмә) кошларны гына куярга тиеш.

**3 вариант.“Кайсы артык?”**

Уен барышы:кошлар арасыннан бала кайсы кошның артык икәнлеген танырга ти

**4 вариант.“Кош агачның кайсы җиренә кунга**

Уен барышы: бала кошны агачның кайсы җиренә(уң,сул якка,өскә,аска) утырганын әйтергә тиеш.

**5 вариант.“Сана һәм әйт”**

Уен барышы: бала кошларны исемләп сана тиеш.



# Уенның нәтиҗәлелеге:

- Балаларның  фикерләү, уйлау сәләте  үстерелә;
- Балаларның кошлар турындагы белемнәре тулыландырыла.
- Сүз байлыгы арта,  сөйләм теле үсә.